**ГРАЖДАННАР ЖЫЕ..Ы КАРАРЫ**

**№1** **01 ноябрь 2025 ел**

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге составына керүче
Кызыл Сукачы авылында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә 2023 елның 01 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:
«Сез, 2026 елда Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Кызыл Сукачы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- территорияләрне төзекләндерүне оештыру (Кызыл Сукачы авылында юлларны кардан чистарту);
- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту (зират коймасы, материал сатып алу һәм урнаштыру).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 20 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 15.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 15, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Кызыл Сукачы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип таныйрга.
2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныйрга:

«Сез, 2026 елда Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Кызыл Сукачы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- территорияләрне төзекләндерүне оештыру (Кызыл Сукачы авылында юлларны кардан чистарту);
- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту (зират коймасы, материал сатып алу һәм урнаштыру).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Әлкәй авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru)
хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы м ниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге башлыгы А.Н.Арсланов

АЛЬКЕЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1602002494
КПП 164301001